# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

(V чакырылыш)

V чакырылышның II утырышы

## КАРАРЫ

«07» ноябрь 2025 ел № 13 Урыссу ш.т.б.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү турында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль законның 22 маддәсе, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында"гы 22.11.2024 ел, № 28 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 50, 51 статьялары, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында»гы 30.04.2025 №15 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 07.10.2025 елның «Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында»гы 30.04.2025 елның 15 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында"гы №8 санлы карары, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 07.10.2025 елның «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында»гы № 9 карары, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында"гы 07.10.2025 ел, № 9 карарына үзгәрешләр кертү хакында"гы 17.10.2025 ел, № 12 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс комиссиясе тарафыннан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен бирелгән конкурс нәтиҗәләрен карап чыкканнан соң, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе итеп Самонина Светлана Петровнаны билгеләргә.

2. Самонина Светлана Петровнаның Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына керешү көне дип 2025 елның 8 ноябрен санарга.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы Шәфигуллин Аяз Әдип улына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Самонина Светлана Петровна белән контракт төзергә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы «Рәсми Татарстан» Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

5. Әлеге карар аңа имза салынган көннән үз көченә керә.

Ютазы муниципаль
районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин